

# 30 октябрь- сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне!

Үзәк өзгеч бер хәтирә булыр
Бу гомернең яман яңгыры»

1991 елдан башлап 30 октябрь - сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтелә. 1921-1953 еллардагы репрессияләр вакытында СССРда барлыгы 6 миллионнан артык кеше зыян күргән дип санала.Төрле елларда илдә барган сәясәт нигезендә административ тәртиптә репрессияләнгәннәрне тагын бер кат искә алу көне бу. Мөлкәтеннән, йорт-җиреннән мәхрүм ителеп, илнең тормыш итү өчен шартлар булмаган ерак төньяк һәм көнчыгыш төбәкләренә сөрелгән миллионлаган корбаннарның язмышын хәтердә яңарту көне. Аларның саны да, исәбе дә төгәл генә билгеле түгел. Төрле чыганакларда мәгълүматлар төрлечә китерелә: берничә йөз меңнәр белән, хәтта берничә миллион белән дә исәпләнә тапталган гомерләр саны.



Түбән Кәминкә авылында яшәүче Зөләйха Гөлюм кызы Нуртдинованың әтисе репрессия корбаны булган. Һәр ел саен диярлек авыл китапханәсендә Зөләйха апа белән очрашу үткәрәбез.

# Кыр бригадиры Голем абзый

Авылда кырчылык бригадиры булып эшләгән өч балалы Гөлем Нуртдиновның (1901) язмышы да фажигале. Ул Кармыш авылының беренче мулласы Җәгъфәр Мөхәммәтшәриф улы нәселен дәвам итүче.Әтисе Нуретдиннең бертуганы имам Талибетдин хәзрәт Хәйретдинов (1869-1921) Тайсуган мәдрәсәсендә укыган , Сарман районы Рангазар авылында гына түгел,бөтен Минзәлә өязендә узенең укымышлылыгы һәм сәүдә эшләренә хирыслыгы белән танылган. Нәселләрендә дин әхелләре күп. Улы Кыям Җәгъфәров(1900-1967) Муса Җәлилләр белән бергә Германиядә әсирлектә булган, соңыннан Лаврентий Берия концлагерьларында интеккән.



Гөлем абзыйны 1941 елнын апрелендә кулга алалар. Дин әхеллэренә теләктәшлек күрсәткән, Себердә җәфа чигүче мулла гаиләләренә сохари,чабаталар үреп, шуны посылка ясап жибәреп яткан, мулла малаен кунакка чакырган, Кармыш мәчетен төзекләндерергә  акча җыярга кирәк, халыкның икмәген  талыйлар, ачлык була, дип, начар хәбәрләр тараткан .Хәтта мәчет китапханәсен ,мәчетнең метрика дәфтәрләрен, гарәпчә төрле тарихи документларны үзендә яшереп саклаган икән. Имештер тегеләй дигән,болай дигән. Колхоз җитәкчеләре, җиде авылдаштан чеп-чи ялган кәгазь яздырып, беркемгә дә зыян салмаган кыр эшләре бригадирын төрмәгә утырта. Һәр авылдашның бер ялганы яки әләге аның бер ел гомерен кискән.

- Һәр доноска бер ел чәпәгәннәр.Бу кешеләр соңыннан булса да вөждан газабы кичерделәрме,зинданда , һавасыз пычрак бүлмәдә ачлыктан ,үпкәсе шөшүдән,авылдашларына рәнжеп үлгән Гөлем абзый рухына дога кылып, Аллахыдан гафу сораргга өлгерделәр микән? Урыс әйтмешли, «наврядли», ялгыш кына булса да төшләренә дә кермәгәндер үкенү хисләре. Ул кыйнауларына карамастан түзгән,үзенә тагылган ялганны танымаган. Ватан сугышының икенче конендә,23 июньдә суд булып,7 елга хөкем итәләр.1943 елда ТАССРда, 9нчы колониядә үлгән.1989 елда акланган.

Репрессия елларында бик шома язылган 58 нче мәддәгә нигезләнеп яна оешкан Советлар илендә бик күп гражданнарның гомерен гаепсезгә кисәләр. Концлагерьларга җыелган халыкның иң зур өлеше ачлы –туклы җан асрап, түләүсез эшче буларак яңа хакимлеккә завод-фабрикалар, юллар,шахталар төзеп бирә,алар хәлсезлектән ат кебек егылып үлә,гарипләнә,бик азлары гына туган җирләренә кайтып җитә,әмма озакка түгел,авыр хезмәттә алган яралары һәм авыртулары кабергә илтеп тыга. Өйләренә кайткан бу «дошманнарны» җирле түрәләр генә түгел,хәтта үз туганнары да шатланып каршы алмаган. Алар аркасында бөтен нәсел –нәсәбенә кара тап төшкән, « бәхетле киләчәккә» бару юллары чикләнгән. РСФСР җинаять кодексының мәшхүр 58нче мәддәсе эчтәлеген кыскача аңлатмасы- шул болгавыр чорның чагылышы. Кемнәрдер уйлап чыгарган бер уч шул кәгазь күпме язмышларны сызып ташлаган.






ЖЕРТВАМ


Тарих сыры катлам –катлам…
Хаклык кайда?
Ялган кайда?
Үткәннәргә күз төшерик,
Ачык түгел хаклык һаман.


« Ә шулай да бер борылып багу,
Гөнах түгел үткән
заманнарга….»